МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

01.11.2019 Казан ш. № 21-95-261

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы администрацияли торган Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан карар кабул итү тәртибен раслау хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының $47^2$ статьясындагы 4 пунктын, “Россия Федерациясе бюджеты системалары бюджетларына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында карарлар кабул итү тәртибенә карата гомуми таләпләр турында” 6 май, 2016 ел, № 393Россия Федерациясе Хөкүмәте карарын тормышка ашыру максатыннан чыгып, б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы администрацияли торган Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан карар кабул итү тәртибен (кушымта итеп бирелә) расларга.
2. Бу боерык кул куелганнан көннән үз көченә керә.
3. Бу боерыкның үтәлешен контрольлектә тотуны Татарстан Республикасы финанс министрының беренче урынбасары – Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаменты директоры М.Д.Фәйзрахмановка йөкләргә.

Министр Р.Р.Гайзатуллин

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 01.11.2019 ел, № 21-95-261 боерыгы белән РАСЛАНДЫ

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы администрацияли торган Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында Татарстан РеспубликасыФинанс министрлыгы тарафыннан карар кабул итү тәртибе

1. Бу Тәртип Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең администраторы (алга таба – Бюджет керемнәре администраторы) булып торучы Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына (алга таба – Бюджет) түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан карар кабул итү кагыйдәләрен һәм шартларын билгели.

2. Билгеләнгән срокта Бюджетка түләнелмәгән түләүләр (Бюджетка түләүләр буенча бурыч) түбәндәге очракларда түләтүгә өметсез дип таныла:

а) Бюджетка түләүләр түләүче физик зат үлгән очракта яки ул Россия Федерациясе гражданлык-процессуаль законы нигезендә билгеләнгән тәртиптә үлгән дип игълан ителгән очракта;

б) Бюджетка түләүләр түләүче-хосусый эшмәкәр “Бөлгенлеккә төшү (банкротлык)” турында 26 октябрь, 2002 ел, № 127-ФЗ Федераль закон нигезендә, бурычлының мөлкәте җитәрлек булмау аркасында Бюджетка түләнелмәгән түләүләр буенча бурычы ягыннан банкрот дип танылган очракта;

в) оешманың мөлкәте җитәрлек булмау аркасында һәм (яки) әлеге оешманың гамәлгә куючылары тарафыннан Россия Федерациясе законы нигезендә билгеләнгән чикләрдә һәм тәртиптә аларны түләтеп булмау аркасында Бюджетка түләнелмәгән түләүләр буенча бурыч ягыннан Бюджетка түләүләр түләүче оешма бетерелгән очракта;

г) суд тарафыннан акт кабул ителеп, аның нигезендә, Бюджет керемнәре администраторы бурычны түләтүнең билгеләнгән срогы (дәгъва срогы) чыгу сәбәпле, Бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтү мөмкинлеген югалткан очракта, шул исәптән Бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтү турында судка гариза тапшыруның кулдан ычкындырылган срогын торгызудан баш тарту хакында суд билгеләмә чыгарган очракта.

д) Бюджетка түләүләр буенча бурыч барлыкка килгәннән соң биш елдан артыграк вакыт узса, “Башкару производствосы турында” 2 октябрь, 2007 ел, № 229-ФЗ Федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 һәм 4 пунктларында күздә тотылган нигезләр буенча башкару производствосының тәгәлләнүе һәм түләтчегә башкару документын кире кайтару турында суд приставы-башкаручы тарафыннан карар чыгарганда, түбәндәге очракларда:

- бурыч күләме, банкротлык турында эш кузгату өчен, бөлгенлеккә төшү (банкротлык) турында Россия Федерациясе законында билгеләнгән бурычлыга карата таләпләр күләменнән артмаганда;

- суд Бюджетка түләүләрне түләүчене банкрот дип тану турында гаризаны кире кайтарганда яки, банкротлык турында эштә кулланыла торган процедуралар үткәрүгә суд чыгымнарын каплау өчен җирәрлек күләмдә средстволар булмау аркасында, банкротлык турында эшне туктатканда.

3. Бу Тәртипнең 2 пунтында күрсәтелгән очраклардан тыш, билгеләнгән срокта түләнелмәгән административ штрафлар, Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында билгеләнгән административ җәза чарасын билгеләү турында карарны үтәүнең дәгъва срогы үтү очрагында, мондый срокны өзеп торуга, туктатып торуга яки озайтуга нигезләр булмаганда, түләтүгә өметсез дип танылa.

4. Бу Тәртипнең 2 пунктындагы “а” пунктчасында күрсәтелгән очракта, Бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану түбәндәге документлар нигезендә кабул ителә:

а) бу Тәртипкә №1 кушымта нигезендәге форма буенча, Бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтүне тәэмин итү буенча күрелгән чаралар турында Бюджет керемнәре администраторы хисабыннан өземтә (алга таба – Өземтә);

б) Бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтүне тәэмин итү буенча күрелгән чаралар турында Бюджет керемнәре администраторының әлеге бурычны түләтүне хәл кылучы бүлек тарафыннан тапшырылган белешмәсе;

в) Бюджетка түләүләр түләүче-физик затның үлемен раслаучы яки аның үлгән дип игълан ителү фактын раслаучы документ.

5. Бу Тәртипнең 2 пунктындагы “б” пунктчасында күрсәтелгән очракта, Бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану түбәндәге документлар нигезендә кабул ителә:

а) өземтә;

б) белешмә;

в) Бюджетка түләүләр түләүче-хосусый эшмәкәрнең банкрот дип танылуы аркасында Хосусый эшмәкәкрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан алынган мәгълүматлардан торган документ.

6. Бу Тәртипнең 2 пунктындагы “в” пунктчасында күрсәтелгән очракта, Бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану түбәндәге документлар нигезендә кабул ителә:

а) өземтә;

б) белешмә;

в) Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 61 статьясындагы 2 пунктында күрсәтелгән нигезләр буенча юридик затны бетерү турында суд карары күчермәләре яки гамәлгә куючылары (катнашучылар) яисә гамәлгә кую документлары нигезендә вәкаләт бирелгән юридик зат органы карары күчермәләре;

г) Бюджетка түләүләр түләүче-оешма бетерелүгә бәйле рәвештә эшчәнлекне туктату турында Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан алынган мәгълүматлардан торган документ.

7. Бу Тәртипнең 2 пунктындагы “г” пунктчасында күрсәтелгән очракта, Бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану түбәндәге документлар нигезендә кабул ителә:

а) өземтә;

б) белешмә;

в) суд акты – Бюджет керемнәре администраторының бурычны түләтүнең билгеләнгән срогы (дәгъва срогы) чыгу сәбәпле, Бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтү мөмкинлеген югалтуы турында, шул исәптән Бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтү турында судка гариза тапшыруның кулдан ычкындырылган срогын торгызудан баш тарту хакында суд билгеләмәсе.

8. Бу Тәртипнең 2 пунктындагы “д” пунктчасында күрсәтелгән очракта, Бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану түбәндәге документлар нигезендә кабул ителә:

а) өземтә;

б) белешмә;

в) “Башкару производствосы турында” 2 октябрь, 2007 ел, № 229-ФЗ Федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 һәм 4 пунктларында күздә тотылган нигезләр буенча башкару документы түләтүчегә кире кайтарылганда, башкару производствосының тәмамлануы турында суд приставы-башкаручының карары.

9. Бу Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән очракта, Бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану түбәндәге документлар нигезендә кабул ителә:

а) өземтә;

б) белешмә;

в) бурычның килеп чыгуын һәм булуын раслаучы документлар (административ хокук бозу турында эш буенча карар) күчермәләре.

10. Тапшырыла торган документлар күчермәләре билгеләнгән тәртиптә расланылган булырга тиеш.

11. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаменты керемнәр бүлеге, бу Тәртип нигезендә, бу Тәртипнең 12 пунктында күрсәтелгән комиссия бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул иткәннән соң 10 эш көне эчендә Бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тануның нигезләрен раслаучы документлар пакетын әзерли.

12. Бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану эшен оештыру максатыннан чыгып, Бюджет керемнәре администраторы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Активлар керү һәм чыгу комиссиясе (алга таба – Комиссия) оештырыла.

13. Комиссия, комиссия рәисен һәм Комиссия секретарен кертеп, Комиссиянең биш әгъзасыннан формалаштырыла. Комиссиянең барлык әгъзалары карарлар кабул иткәндә бертигез хокукларга ия була.

14. Комиссиянең Бюджетка түләү буенча һәр бурыч суммасы буенча карары индивидуаль кабул ителә.

15. Комиссия утырышлары кирәк булганга карап үткәрелә. Комиссия утырышын үткәрү датасын, вакытын һәм урынын аның рәисе яисә рәис вазифаларын башкаручы зат билгели.

Комиссия утырышлары Комиссия рәисе яки аның вазифаларын башкаручы зат тарафыннан үткәрелә һәм беркетмә белән рәсмиләштерелә, аңа утырышта катнашучы Комиссия әгъзалары кул куя.

Комиссия утырышында Комиссия әгъзаларының ким дигәндә яртысы катнашса, Комиссия утырышы, узды, дип санала.

16. Комиссия документларны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча, җиде календарь көненнән дә соңга калмаган вакыт эчендә, түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) Бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип танырга;

б) Бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип танудан баш тартырга. Әлеге карар Бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында мәсьәләне кабат карап тикшерүгә комачауламый.

17. Комиссия карары, утырышта катнашкан Комиссия әгъзалары санынна күпчелек тавыш белән, ачык тавыш бирү нигезендә кабул ителә.

18. Комиссия беркетмәсе нигезендә, бу Тәртипкә №2 кушымта нигезендәге форма буенча, Бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында акт (алга таба – Акт) бастырып чыгарыла.

Акт ике нөсхәдә төзелә һәм аңа Комиссия рәисе һәм утырышта катнашкан Комиссиянең барлык әгъзалары кул куя.

19. Акт җиде эш көне эчендә Татарстан Республикасы финанс министры тарафыннан раслана.

20. Бюджетка түләүләр буенча түләтүгә өметсез дип танылган бурычны гамәлдән чыгару, расланылган Акт нигезендә, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының керемнәр бүлеге тарафыннан хәл ителә.

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы администрацияли торган Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан карар кабул итү тәртибенә №1 кушымта

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы администрацияли торган Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча исәпкә алынган бурыч суммалары турында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы хисабыннан

ӨЗЕМТӘ

________________________________________________________________________
(оешма атамасы, ИНН/КПП, физик затның Ф.И.О., ИНН (булганда)

________________ елга

| п/п | КБК | Түләү атамасы | Бурычның килеп чыгу датасы (срогы) | Бурыч суммасы, сумнарда |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |

Татарстан Республикасы
Финанс министрлыгы
Казначылык департаментының
керемнәр бүлеге начальнигы

(имза) (Ф.И.О.)

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы администрацияли торган Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан карар кабул итү тәртибенә №2 кушымта

РАСЛЫЙМ:
Татарстан Республикасы
финанс министры

___________ ______________
(имза) (Ф.И.О.)
«__» _____________ 20__ г.

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы администрацияли торган Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында
АКТ № ___

«__» ___________ 20___ ел Казан ш.

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Активлар керү һәм чыгу буенча комиссиясе, тапшырылган документлар буенча ________________ <*> бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында мәсьәләне карады

___________________________________________________________________________
(оешманың тулы атамасы (физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме)

___________________________________________________________________________
Салым түләүченең идентификация номеры, төп дәүләт теркәү номеры

___________________________________________________________________________
(салым түләүче физик затның идентификация номеры)

Татарстан Республикасы бюджетына түләү буенча
___________________________________________________________________________
(бурыч китереп чыгарган түләү буенча мәгълүматлар <**>, бурычны исәпкә алу өчен КБК,

___________________________________________________________________________
аның атамасы)

түләүләр буенча бурыч суммасы - _______________,
Комиссия карар кабул итте:
___________________________________________________________________________
(Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы администрацияли торган

___________________________________________________________________________

Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча түләтүгә өметсез дип тану турында карарлар кабул итү тәртибенең 16 пункты нигезендә Комиссия тарафыннан

___________________________________________________________________________

кабул ителгән карарларның берсе күрсәтелә

___________________________________________________________________________

Акт 2 нөсхәдә төзелде.

Комиссия рәисе: ____________________ ____________________
(Ф.И.О.) (имза)

Комиссия әгъзалары: ____________________ ____________________
(Ф.И.О.) (имза)

____________________ ____________________
(Ф.И.О.) (имза)

____________________ ____________________
(Ф.И.О.) (имза)

____________________ ____________________
(Ф.И.О.) (имза)

--------------------------------

<*> - документларның атамалары һәм реквизитлары күрсәтелә.

<**> - бурыч китереп чыгарган түләү атамасы, таләпләр куюга нигез итеп алынган документлар (карарлар һ.б.) реквизитлары күрсәтелә.